Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
СОВЕТЫ

# КАРАР

2020 елның 30 декабре № 5/3

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Административ комиссиясен төзү буенча вәкаләтле орган турында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану турында» 2020 елның 19 ноябрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетын Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Административ комиссиясен төзү буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетына үзенең норматив хокукый акты белән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Административ комиссиясе составын, рәисен, рәис урынбасарын, җаваплы сәркатибен һәм әгъзаларын билгеләргә, аның эш регламентын расларга.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Административ комиссиясенең вәкаләтләре вакытын беренче утырыш уздырылган көннән 5 ел итеп билгеләргә.

4. Әлеге Карар, гамәлдәге законнарда билгеләнгән башка вакытта үз көченә керә торган нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көнне үз көченә керә.

Глава Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан, Председатель Совета Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан: М.Р. Гафаров